**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЯҢА ЧИШМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 24 нче сентябреннән № 37-139

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 28 декабрендәге 17-62 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 28 декабрендәге 17-62 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 19.12.2023 №32-125; 28.03.2024 №34-129 карарлары редакциясендә) (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2. Нигезләмәнең 1.4 пункытында «Башлык» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 2.9 пунктының икенче абзацында «Җирлек башлыгы» сүзләрен «Яңа Чишмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Нигезләмәнең 3.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.7 Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында карар (күрсәтмә) Яңа Чишмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кабул ителә һәм имзалана.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү комиссиясе рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы В.М. Козлов